| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.05.2014 № 254

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 26 маенда теркәлде, №2315

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 10.05.2011 ел, №244
боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгында дәүләти
гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын
биләүгә конкурс үткәрү методикасына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1 февраль, 2005 ел, №112 Россия Федерациясе Президенты Указы (19.03.2014 елгы ред.) нигезендә, боерык бирәм:

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү методикасын раслау турында” 10.05.2011 ел, №244 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү методикасына (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2011 елның 2 июнендә теркәлгән, №1238) (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.07.2013 ел, №455 үзгәрешләр белән) (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2013 елның 14 августында теркәлгән, №1970) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның икенче абзацында “Министрлыкның Интернет челтәрендәге рәсми сайтында” дигән сүзләрне “Министрлыкның һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат

системасының рәсми сайтларында ” дигән сүзләргә алыштырырга;

6 пунктның “г” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“г) кирәкле һөнәри белемен, квалификациясен һәм эш стажын раслаучы документлар:

нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлегенә тәүге тапкыр керешелгән очраклардан тыш) яки гражданинның хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган белеме һәм квалификациясе турында документлар күчермәләре, шулай ук, гражданинның теләгенә карап, өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча вазыйфасында күтәрелүен яки квалификациясенең күтәрелүен раслаучы документлар күчермәләре, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар күчермәләре;”;

9 пунктның беренче абзацында “аларны кабул итү турында игълан иткән көннән соң” дигән сүзләрне “аларны кабул итү турында белдерүне Министрлыкның рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырган көннән соң” дигән сүзләргә алыштырырга;

18 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“Комиссия гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңмәгән, әмма һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары югары бәяләнгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерындагы карар кабул итүгә хокуклы.”;

20 пунктта “Министрлыкның Интернет челтәрендәге рәсми сайтында” дигән сүзләрне “Министрлыкның һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында” дигән сүзләргә алыштырырга.

Министр А.Р.Шәфигуллин